Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

# АРЧА ШӘҺӘР СОВЕТЫ
# КАРАРЫ

**23 октябрь 2023 ел** **№ 108**

**«Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Арча шәһәр Советының 2017 елның 13 сентябрендәге 69 номерлы карарын (30.05.2019 № 121, 19.03.2020 № 144 үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип тану турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктына, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 статьясына ярашлы рәвештә, Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Арча район Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүдә түләүсез нигездә катнашу өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 13 сентябрендәге 69 номерлы карары;

- «Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүдә түләүсез нигездә катнашу өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017

елның 13 сентябрендәге 69 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 30 маендагы 121 номерлы карары;

- «Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүдә түләүсез нигездә катнашу өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 13 сентябрендәге 69 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 19 мартындагы 144 номерлы карары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге
башлыгы урынбасары,
Арча шәһәр Советы рәисе урынбасары Г.Х.Нигъмәдҗанова